**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында аттестацияләү һәм квалификация имтиханы уздыруны оештыру турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 9 сентябрендәге 1387 номерлы карары нигезендә расланган Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәткәрләрен аттестацияләүне уздыруның бердәм методикасы нигезләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында аттестацияләү һәм квалификация имтиханы уздыруны камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында аттестацияләү һәм квалификация имтиханы уздыруны оештыру турында» 2011 елның 3 мартындагы ПУ-94 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 20 мартындагы ПУ-240 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында аттестацияләү һәм квалификация имтиханы уздыруны оештыру турында нигезләмәгә, аны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 09 сентябрь
№ ПУ-696

Татарстан Республикасы
Президентының
2021 елның « 09 » сентябрендәге
ПУ-696 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында аттестацияләү һәм квалификация имтиханы уздыруны оештыру турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының аттестацияләү комиссиясен формалаштыру һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә (алга таба – граждан хезмәткәрләре) карата Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында аттестацияләү һәм квалификация имтиханын уздыру эшен оештыру мәсьәләләрен җайга сала.

2. Аттестацияләү граждан хезмәткәренең һөнәри хезмәт эшчәнлеген бәяләү нигезендә аның Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында биләгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына туры килүен билгеләү максатында уздырыла.

Граждан хезмәткәрләрен аттестацияләү йомгаклары түбәндәгеләр өчен кулланыла:

аларның һөнәри эшчәнлекләрен бәяләү;

вазыйфаи бурычларын намус белән үтәүләренә һәм һөнәри осталык дәрәҗәләрен күтәрүгә этәргеч бирү;

һөнәри үсеш юнәлешләрен билгеләү;

граждан хезмәткәрләренең һөнәри хезмәт эшчәнлеген бәяләү йомгаклары нигезендә эшкә алучы вәкиле тарафыннан кабул ителә торган карарларның нигезле булуын тәэмин итү;

вазыйфада үсеш буларак граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервын формалаштыру.

3. Дәүләт хезмәткәрләренә квалификация имтиханы граждан хезмәткәренә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте класслы чинын (алга таба – класслы чин) бирү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә уздырыла.

4. Граждан хезмәткәрләрен аттестацияләү һәм квалификация имтиханы Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының аттестацияләү комиссиясе (алга таба – аттестацияләү комиссиясе) тарафыннан уздырыла.

Граждан хезмәткәрләрен аттестацияләүне һәм квалификация имтиханы уздыруны оештыру ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (алга таба – Департамент) тарафыннан тормышка ашырыла.

II. Аттестацияләү комиссиясен формалаштыру

5. Аттестацияләү комиссиясенең составы Татарстан Республикасы Президенты боерыгы белән раслана.

6. Аттестацияләү комиссиясе составына эшкә алучы вәкиле һәм (яисә) аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар (шул исәптән дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәдән һәм аттестацияләнергә тиешле граждан хезмәткәре Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын били торган (алга таба – граждан хезмәте вазыйфасы) бүлекчәдән) бәйсез экспертлар, шулай ук аттестацияләнә торган граждан хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе яисә аның урынбасары кертелә.

Граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычлары үзенчәлекләренә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында берничә аттестацияләү комиссиясе төзелергә мөмкин.

7. Бәйсез экспертлар сыйфатында аттестацияләү комиссиясе составына фән, мәгариф һәм башка оешмаларның граждан хезмәткәрләренең һөнәри хезмәт эшчәнлегенең тиешле өлкәләрендә һәм төрләрендә, кадрлар технологияләре һәм дәүләт граждан хезмәте мәсьәләләрендә белгеч булган вәкилләре кертелә. Бәйсез экспертлар саны аттестацияләү комиссиясе әгъзаларының гомуми санының дүрттән бер өлешеннән ким булмаска тиеш.

8. Алар буенча вазыйфаи бурычлар үтәү дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлардан файдалану белән бәйле булган граждан хезмәте вазыйфаларын башкаручы граждан хезмәткәрләрен аттестацияләүне уздыру өчен аттестацияләү комиссиясе составы дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары нигезләмәләрен исәпкә алып формалаштырыла.

9. Аттестацияләү комиссиясе составы аттестацияләү комиссиясенең кабул ителүче карарларына йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр конфликты килеп чыгу мөмкинлеген булдырмаслык итеп формалаштырыла.

Департамент аттестацияләү комиссиясе әгъзаларының шәхси кызыксынулары турындагы мәгълүматларга таянып, алар арасында аттестацияләү комиссиясе карарларына йогынты ясардай мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлеген булдырмау өчен чаралар күрә. Департамент аттестацияләү комиссиясе әгъзасын, мәнфәгатьләр каршылыгына китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килгән очракта, үзенә бу турыда хәбәр бирергә кирәклеге турында кисәтә. Аттестацияләү комиссиясе утырышларында катнашу яисә комиссия тарафыннан аерым мәсьәләләр карап тикшерелү белән бәйле рәвештә үзендә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлеген ачыклаган очракта

аттестацияләү комиссиясе әгъзасы аттестацияләү комиссиясе утырышында яисә тиешле карарны кабул итүдә катнашмый.

10. Аттестацияләү комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, аттестацияләү комиссиясе секретаре һәм әгъзаларыннан тора. Аттестацияләү комиссиясенең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә бер үк хокукка ия.

11. Аттестацияләү комиссиясе рәисе булмаган очракта аның вазыйфаларын аттестацияләү комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

12. Аттестацияләү комиссиясе әгъзасы булып торган граждан хезмәткәрен аттестацияләү чорында бу комиссиядә аның әгъзалыгы туктатылып тора.

13. Аттестацияләү комиссиясе секретаре:

рәискә, рәис урынбасарына, аттестацияләү комиссиясе әгъзаларына аттестацияләү үткәрүнең көне, вакыты һәм урыны турында хәбәр итә;

аттестацияләү комиссиясе утырышы беркетмәсен алып бара;

әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә форма буенча граждан хезмәткәрләренең аттестацияләү кәгазьләрен тутыра һәм аттестацияләү узган граждан хезмәткәрләрен кул куйдырып, аттестацияләү кәгазьләре белән таныштыра;

аттестацияләү узган граждан хезмәткәрләренең аттестацияләү кәгазьләрен һәм башка материалларны Департаментка тапшыруны тәэмин итә;

аттестацияләү комиссиясе утырышлары беркетмәсе тегеп куела торган номенклатура эшен алып бара;

аттестацияләү комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү белән бәйле башка вазыйфаларны үти.

14. Аттестацияләү комиссиясе утырышы, әгәр анда әгъзаларының кимендә өчтән ике өлеше катнашса, эш алып барырга хокуклы дип санала.

Аттестацияләү комиссиясенең граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән әгъзалары гына катнашкан утырышларын уздыру тыела.

## III. Граждан хезмәткәрләрен аттестацияләү уздыруны оештыру

15. Аттестация уздыру графигы аттестацияләнә торган граждан хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе фикерен, алдагы аттестацияне уздыру датасын исәпкә алып, Департамент тарафыннан төзелә һәм шул елның 1 февраленә кадәр һәр елны Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә раслау өчен бирелә. Аттестация уздыру графигы аттестацияләнә торган һәр граждан хезмәткәренә аттестация башланганчы кимендә бер ай кала җиткерелә.

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең аттестация уздыру турындагы боерыгына түбәндәге тәкъдимнәрне кертү зарур:

аттестацияләү комиссиясе эшенең сроклары һәм тәртибе турында;

аттестация уздыру графигын һәм аттестацияләнергә тиешле граждан хезмәткәрләре исемлекләрен раслау, аттестацияләнә торган һәр граждан хезмәткәренең мәгълүматлар белән танышуын оештыру турында;

аттестацияләнә торган граждан хезмәткәренең аттестация уздырыла торган чорда вазыйфаи бурычларын үтәве турында турыдан-туры җитәкчесе тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча тутырыла торган бәяләмә (алга таба – бәяләмә) әзерләү һәм аны аттестацияләү комиссиясенә тапшыру кирәклеге турында;

граждан хезмәткәрләренең һөнәри хезмәт эшчәнлегенә граждан хезмәте категорияләрен һәм төркемнәрен, һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәләрен һәм төрләрен исәпкә алып кулланыла торган бәяләү ысуллары турында;

граждан хезмәткәрен бәяләмә белән аттестация башланганчы ике атнадан да соңга калмыйча таныштыру турында;

Департамент тарафыннан аттестацияләү комиссиясе эше өчен кирәкле материалларны әзерләү турында;

бәйсез экспертларга аттестацияләү комиссиясен уздыру урыны һәм вакыты турында мәгълүмат җибәрү.

16. Граждан хезмәткәрен аттестацияләү өч елга бер тапкыр уздырыла. Чираттан тыш уздырыла торган аттестация датасы алдагы аттестацияне уздыру срокларына карамастан билгеләнә ала. Чираттан тыш аттестация түбәндәге очракларда уздырыла ала:

а) хезмәт контрактында катнашучы якларның килешүе нигезендә граждан хезмәткәренең һөнәри хезмәт эшчәнлеге турындагы еллык хисап йомгакларын исәпкә алып;

б) билгеләнгән тәртип буенча түбәндәгеләр турында карар кабул ителгәннән соң эшкә алучы вәкиле карары буенча:

дәүләт органында граждан хезмәте вазыйфалары кыскартылу турында;

граждан хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартларын үзгәртү турында.

Әлеге пунктның «а» пунктчасы нигезендә уздырыла торган чираттан тыш аттестацияне үткәрү башлангычын эшкә алучы вәкиле яисә граждан хезмәткәре тәкъдим итәргә мөмкин. Хезмәт контрактында катнашучы бер як хезмәт контрактында катнашучы икенче якның башлангычы белән килешкән очракта, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең чираттан тыш аттестация уздыру турында боерыгы чыгарыла.

Үзенә карата чираттан тыш аттестация уздыру башлангычы белән чыккан граждан хезмәткәре, чираттан тыш аттестация уздыруга нигез булып торган сәбәпләрне күрсәтеп, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә гариза юллый.

17. Аттестацияләү комиссиясе эшендә кирәк булачак һәм аттестацияләү комиссиясенә аттестация башланганчы ике атнадан да соңга калмыйча тапшырыла торган мәҗбүри документларга түбәндәгеләр керә:

аттестациялəнергə тиешле граждан хезмəткəренə билгелəнгəн тəртиптə тутырылган, структур бүлекчə җитəкчесе яисə граждан хезмəткəренең турыдан-туры җитəкчесе кул куйган һəм дəүлəт хезмəткəренең турыдан-туры җитəкчесе тарафыннан расланган бəялəмə;

граждан хезмəткəренең алдагы аттестациялəре күрсəткечлəре (булган очракта) китерелгəн аттестациялəү кəгазе.

Әлеге документлар электрон документ рəвешендə, шул исəптəн Татарстан Республикасы дəүлəт хакимияте органнарының электрон документ əйлəнеше бердəм ведомствоара системасын файдаланып та, əзерлəнергə мөмкин.

18. Бəялəмəгə граждан хезмəткəренең аттестациялəнү чорында йөклəмəлəрне үтəве һəм аның тарафыннан əзерлəнгəн документлар проектлары хакында белешмəлəр теркəп бирелə. Бəялəмəне əзерлəү өчен граждан хезмəткəренең һөнəри хезмəт эшчəнлеге турында еллык хисаплар файдаланыла.

19. Департамент тарафыннан аттестациялəү комиссиясе утырышына аттестациялəнə торган граждан хезмəткəренең шəхси документлары тупланмасыннан аның белгечлеге, əзерлек юнəлеше, граждан хезмəткəре стажының яисə белгечлеге, əзерлеге юнəлеше буенча стажының дəвамлылыгы, дəүлəт органының кадрлар резервына кертелүе, һөнəри үсеш чараларында катнашуы, граждан хезмəте узган чорда бүлəклəнүе, дисциплинар җавапка тартылуы турында, шулай ук аттестация максатларына яраклы башка əһəмиятле мəгълүмат кертелгəн өземтə əзерлəнə.

20. Департамент аттестациялəү башлануга кадəр кимендə ике атна алдан аттестациялəнүче граждан хезмəткəрен бəялəмə белəн таныштырырга тиеш. Бу вакытта аттестациялəнүче граждан хезмəткəре аттестациялəү комиссиясенə аттестациялəнү чорында үзенең һөнəри хезмəт эшчəнлеге турында өстəмə белешмəлəр, шулай ук бирелгəн бəялəмə белəн ризасызлыгы турында гариза яисə бəялəмəгə аңлатма язуы бирергə хокуклы.

21. Аттестациялəү аттестациялəнүче граждан хезмəткəрен аттестациялəү комиссиясе утырышына чакырып уздырыла. Граждан хезмəткəре аттестация уздыру көнендə җитди сəбəп буенча хезмəт урынында булмаса, аттестация уздыру вакыты соңракка күчерелə.

Граждан хезмəткəре аттестациялəү комиссиясе утырышына мөһим сəбəпсез килмəсə яисə аттестациялəнүдəн баш тартса, граждан хезмəткəре Россия Федерациясе дəүлəт граждан хезмəте турында законнар нигезендə дисциплинар җаваплылыкка тартыла, ə аттестациялəү соңрак вакытка күчерелə.

22. Аттестациялəү комиссиясендə, аларның берсе дə аттестациялəү комиссиясе составына кертелмəгəн очракта, аттестациялəнүче граждан хезмəткəренең турыдан-туры җитəкчесе яисə аның урынбасары катнаша.

23. Аттестациялəү комиссиясе бирелгəн документларны карый, аттестациялəнүче граждан хезмəткəре чыгышын, ə кирəк булган очракта –

граждан хезмәткәренең һөнәри хезмәт эшчәнлеге турында аның турыдан-туры җитәкчесе белдерүен тыңлый.

Аттестацияләнүче граждан хезмәткәре аттестацияләү комиссиясенә аттестацияләнү чорында үзенең һөнәри хезмәт эшчәнлеге турында өстәмә белешмәләр биргән очракта, аттестацияләү комиссиясе әлеге белешмәләрне караганнан соң, граждан хезмәткәрен аттестацияләүне аттестацияләү комиссиясенең аннан соңгы утырышына күчерергә мөмкин.

24. Аттестация барышында аттестацияләү комиссиясе граждан хезмәткәренең һөнәри хезмәт эшчәнлегенә түбәндәге характеристикалардан чыгып бәяләмә бирә:

граждан хезмәткәренең тиешле бүлекчә (яисә Татарстан Республикасы Президенты Аппараты) алдында торган бурычларны хәл итүгә юнәлтелгән мәсьәләләрне (документларны) хәл итүдә (эшләүдә) катнашуы;

граждан хезмәткәре башкара торган һөнәри хезмәт эшчәнлегенең катлаулылыгы, аның файдалылыгы һәм нәтиҗәлелеге;

һөнәри белем дәрәҗәсенә, граждан хезмәте яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эшчәнлеге стажына, вазыйфаи бурычларын башкару өчен кирәкле белем һәм күнекмәләренә, шулай ук эшкә алучы вәкиленең тиешле карары булган очракта – белгечлегенә, әзерлеге юнәлешенә туры килүе;

граждан хезмәткәренең хезмәт дисциплинасын һәм чикләүләрне үтәмәве, тыюларны бозуы, Россия Федерациясенең граждан хезмәте һәм коррупциягә каршы көрәшү турындагы законнарында билгеләнгән хезмәт урынында тәртипкә билгеләнгән таләпләрне һәм йөкләмәләрне үтәмәве турында расланган фактларның булмавы.

25. Аттестацияләү комиссиясе граждан хезмәткәренең һөнәри хезмәт эшчәнлегенә бәяләмә нигезендә шәхси документлары тупланмасыннан Департамент тарафыннан бирелгән өземтәдә китерелгән, әлеге Нигезләмәнең 19 пунктында күрсәтелгән мәгълүматны исәпкә алып, шулай ук аттестацияләнә торган граждан хезмәткәренең үзе турында биргән мәгълүматын тыңлау нигезендә аның барышында аттестацияләнә торган граждан хезмәткәренә аның һөнәри хезмәт эшчәнлеген бәяләүгә юнәлтелгән сораулар бирелергә мөмкин, бәя бирә.

Граждан хезмәткәренең һөнәри һәм һөнәри хезмәт эшчәнлегенә кагылышлы шәхси сыйфатлары турында фикер алышу объектив һәм яхшы мөнәсәбәтле булырга тиеш.

Аттестацияләнә торган граждан хезмәткәре аттестацияләү комиссиясе утырышында видеоконференция форматында (техник мөмкинлек булган очракта) катнашырга мөмкин.

Граждан хезмәткәренең һөнәри хезмәт эшчәнлегенә бәя бирү биләгән граждан хезмәте вазыйфасы буенча квалификация таләпләренә туры килүен, аның тиешле бүлекчә (Татарстан Республикасы Президенты Аппараты) алдына куелган бурычларны хәл итүдә катнашуын, башкарган эшенең катлаулылыгын, аның файдалылыгы һәм нәтиҗәлелеген, башкарылган

йөкләмәләр һәм әзерләнгән документлар проектларының санын һәм сыйфатын да кертеп, билгеләүне күздә тота.

Шул ук вакытта граждан хезмәткәренең вазыйфаи регламентны үтәве йомгаклары, граждан хезмәткәренең һөнәри белемнәре һәм эш тәҗрибәсе, граждан хезмәткәренең хезмәт дисциплинасын һәм чикләүләрне үтәмәве, тыюларны бозуы, Россия Федерациясенең граждан хезмәте һәм коррупциягә каршы көрәшү турындагы законнарында билгеләнгән хезмәт урынында тәртипкә билгеләнгән таләпләрне һәм йөкләмәләрне үтәмәве турында расланган фактларның булмавы, ә башка граждан хезмәткәрләренә карата оештыру-боеру вәкаләтләре булган граждан хезмәткәрен аттестацияләгәндә – шулай ук оештыру сәләте исәпкә алынырга тиеш.

26. Аның буенча вазыйфаи бурычларны башкару дәүләт сере булып торган мәгълүматларны файдалану белән бәйле граждан хезмәте вазыйфасын башкаручы граждан хезмәткәрен аттестацияләүне уздыру өчен Департамент тарафыннан дәүләт хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе белән бергәләп граждан хезмәткәренең һөнәри хезмәт эшчәнлеген дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларны файдаланмыйча гына бәяләү мөмкинлеге билгеләнә. Бу очракта граждан хезмәткәрен аттестацияләү аттестацияләү комиссиясе тарафыннан дәүләт сереннән файдалану рөхсәт ителмәгән затлар катнашуында уздырылырга мөмкин.

Мондый граждан хезмәткәренең хезмәт эшчәнлеген дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларны файдаланмыйча гына бәяләү мөмкинлеге булмаганда, аттестацияләү комиссиясе составы дәүләт сереннән файдалануга рөхсәт бирелгән затлардан оештырыла.

27. Граждан хезмәткәре һәм аның турыдан-туры җитәкчесе үзләре булмаганда, аттестацияләү комиссиясе карары утырышта катнашкан комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, граждан хезмәткәре үзе биләгән граждан хезмәте вазыйфасына туры килә дип таныла.

28. Граждан хезмәткәрен аттестацияләү нәтиҗәләре буенча аттестацияләү комиссиясе тарафыннан түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

а) граждан хезмәтендә биләгән вазыйфага туры килә;

б) граждан хезмәтендә биләгән вазыйфага туры килә һәм билгеләнгән тәртиптә вазыйфада үсеш буларак (граждан хезмәткәре биләгән вазыйфа кергән граждан хезмәте вазыйфалары төркемен күрсәтеп, яки граждан хезмәткәрен билгеләп кую мөмкин булган югарырак вазыйфалар төркемен күрсәтеп) граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен кадрлар резервына кертүгә тәкъдим ителә;

в) өстәмә һөнәри белем алу шарты үтәлгәндә, граждан хезмәтендә биләгән вазыйфага туры килә;

г) граждан хезмәтендә биләгән вазыйфага туры килми.

29. Граждан хезмәткәренә аттестация уздыру йомгаклары буенча, шулай ук аның киләчәк һөнәри үсеше һәм вазыйфаи үсеше максатларында

аттестацияләү комиссиясе тарафыннан граждан хезмәткәрен өстенлекле тәртиптә вазыйфаи бурычларын башкару өчен кирәкле һөнәри белемнәр алуга юнәлтелгән программа буенча өстәмә һөнәри белем алырга юллау тәкъдим ителергә мөмкин.

30. Граждан хезмәткәре өстәмә һөнәри белем алудан яисә граждан хезмәтенең башка вазыйфасына күчерүдән баш тарткан очракта, эшкә алучы вәкиле Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турындагы законнары нигезендә граждан хезмәткәрен биләгән граждан хезмәткәре вазыйфасыннан азат итәргә һәм граждан хезмәтеннән чыгарырга хаклы.

31. Аттестациядән соң бер ай вакыт узгач, әлеге аттестация йомгакларына нигезләнеп граждан хезмәткәрен граждан хезмәтенең башка вазыйфасына күчерү яисә аны граждан хезмәтеннән чыгару тыела. Граждан хезмәткәре авырган чор яисә аның еллык түләүле отпуск вакыты әлеге срокка керми.

32. Аттестацияләү комиссиясе карары һәм тавыш бирү нәтиҗәләре аттестацияләү комиссиясе утырышы беркетмәсендә теркәлә, ул рәис, рәис урынбасары, аттестацияләү комиссиясе секретаре һәм утырышта катнашкан әгъзалары тарафыннан имзалана.

33. Аттестацияләү нәтиҗәләре аттестацияләнгән граждан хезмәткәрләренә турыдан-туры тавыш бирүгә йомгак ясалганнан соң аттестацияләү комиссиясе рәисе тарафыннан хәбәр ителә.

Аттестацияләү нәтиҗәләре граждан хезмәткәренең аттестацияләү кәгазенә языла.

Аттестацияләү кәгазе рәис, рәис урынбасары, аттестацияләү комиссиясе секретаре һәм утырышта катнашкан әгъзалар тарафыннан имзалана.

Граждан хезмәткәре аттестацияләү кәгазе белән таныша һәм кул куя.

34. Граждан хезмәткәренең аттестацияләү кәгазе һәм бәяләмә аттестацияләү уздырганнан соң, өч көннән дә соңга калмыйча, аттестацияләү комиссиясе секретаре тарафыннан Департаментка граждан хезмәткәренең шәхси документлары тупланмасына теркәп кую өчен тапшырыла.

Граждан хезмәткәрләрен аттестацияләү материаллары аттестация узганнан соң җиде көннән дә соңга калмыйча, Департамент тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә һәм (яисә) Татарстан Республикасы Президентына тапшырыла.

35. Аттестация уздырылганнан соң бер ай дәвамында аның нәтиҗәләре нигезендә Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе боерыгы чыгарыла, ул түбәндәгеләрне күздә тота:

а) граждан хезмәткәрен вакантлы граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән тәртиптә вазыйфаи үсеш буларак кадрлар резервына кертү;

б) граждан хезмәткәрен яңадан һөнәри әзерлек узарга яисә квалификациясен күтәрергә җибәрү;

в) граждан хезмәтенең түбәнрәк вазыйфасына төшерү.

Граждан хезмәткәре Россия Федерациясе законнары нигезендә аттестация йомгакларына шикаять бирә ала.

## IV. Квалификация имтиханын уздыруны оештыру

36. Квалификация имтиханын граждан хезмәтенең югары вазыйфалар төркеменә караучы «җитәкчеләр» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче граждан хезмәткәрләреннән тыш, алар белән билгеле бер вакытка хезмәт контракты төзелгән граждан хезмәткәрләре тапшыра.

37. Квалификация имтиханы түбәндәге очракларда уздырыла:

а) класслы чины булмаган граждан хезмәткәренә ул биләгән граждан хезмәте вазыйфасы буенча беренче класслы чин бирү мәсьәләсен хәл иткәндә;

б) граждан хезмәткәренә, ул граждан хезмәткәренә бирелә торган класслы чиннан югарырак яисә аңа тигез класслы чин каралган граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен алдагы класслы чинда үтү өчен билгеләнгән вакыт узганнан соң, граждан хезмәткәренә бирелүче граждан хезмәте вазыйфасын биләү буенча чираттагы класслы чинны граждан хезмәткәренә бирү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә;

в) граждан хезмәткәрен граждан хезмәтенең югарырак вазыйфасына билгеләп куйганнан соң, әгәр бу вазыйфа өчен әлеге граждан хезмәткәре ия булган класслы чиннан югарырак класслы чин каралган булса, граждан хезмәткәренә класслы чин бирү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә.

Әлеге пунктның «а» һәм «в» пунктчаларында каралган очракларда, квалификация имтиханы сынау чорын уңышлы узганнан соң, ә граждан хезмәткәренә сынау билгеләнмәсә, граждан хезмәткәре граждан хезмәте вазыйфасына билгеләнгәннән соң кимендә өч айдан соң уздырыла.

38. Граждан хезмәткәре инициативасы буенча уздырылучы квалификация имтиханы чираттан тыш дип санала һәм граждан хезмәткәре тарафыннан класслы чин бирелү турында язма рәвештә гариза бирелгән көннән өч айдан да соңга калмыйча уздырыла.

39. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең квалификация имтиханы уздыру турындагы карары елга бер тапкырдан күбрәк һәм өч елга бер тапкырдан азрак кабул ителә алмый. Әлеге карар Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе боерыгы рәвешендә кабул ителә, аның проектын эшләүне Департамент башкара.

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең квалификация имтиханы уздыру турындагы боерыгында түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) квалификация имтиханын уздыруның көне һәм вакыты;

б) квалификация имтиханы тапшырырга тиешле граждан хезмәткәрләре исемлеге;

в) квалификация имтиханы уздыру өчен кирәк булган документлар исемлеге.

40. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең квалификация имтиханы булачагы турында карары Департамент тарафыннан граждан хезмәткәренә аны уздыруга кимендә бер ай кала җиткерелә.

41. Квалификация имтиханы уздырырга кимендә бер ай кала граждан хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе аттестацияләү комиссиясенә граждан хезмәткәренең белеме, күнекмәләре һәм осталыгы (һөнәри дәрәҗәдә) турында һәм аңа классны чин бирү мөмкинлеге турында бәяләмә әзерли (3 нче кушымта).

42. Департамент граждан хезмәткәрен әлеге Нигезләмәнең 41 пунктында күрсәтелгән бәяләмә белән квалификация имтиханы уздыруга кадәр ике атнадан да соңга калмыйча таныштырырга тиеш.

Граждан хезмәткәре аттестацияләү комиссиясенә югарыда күрсәтелгән бәяләмә белән килешмәве турында гариза бирергә хокуклы.

43. Аттестацияләү комиссиясе квалификация имтиханын уздырганда граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентлары таләпләре нигезендә граждан хезмәткәрләре үти торган эшнең катлаулылыгыннан һәм җаваплылыгыннан чыгып, федераль законнарга һәм граждан хезмәткәренең һөнәри сыйфатларын бәяләүнең Россия Федерациясе норматив хокукый актларына каршы килми торган ысулларын кулланып, имтихан процедуралары нигезендә граждан хезмәте вазыйфасын биләү буенча вазыйфаи бурычларын үтәү белән бәйле сораулар буенча индивидуаль әңгәмәне һәм тест үткәрүне дә кертеп, граждан хезмәткәренең белемен, тәҗрибәсен һәм осталыгын (һөнәри дәрәҗәсен) бәяли.

Граждан хезмәткәренең һөнәри сыйфатларын бәяләү ысулын аттестацияләү комиссиясе сайлап ала. Бу вакытта квалификация имтиханы уздырганда граждан хезмәткәрен тестлаштыру аттестацияләү комиссиясенә квалификация имтиханы уздыруга кадәр бер айдан да соңга калмыйча квалификация имтиханы тапшыручы граждан хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе тапшырган тестлаштыру өчен теоретик мәсьәләләр исемлеге буенча башкарыла.

44. Квалификация имтиханы нәтиҗәләре турында карар аттестацияләү комиссиясе тарафыннан, граждан хезмәткәре һәм аның турыдан-туры җитәкчесе булмаганда, утырышта катнашучы аттестацияләү комиссиясе әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, граждан хезмәткәре квалификация имтиханын биргән дип танымыла.

45. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча аттестацияләү комиссиясе тарафыннан түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

а) граждан хезмәткәре квалификация имтиханын бирде дип танырга һәм аны классны чин бирү өчен тәкъдим итәргә;

б) граждан хезмәткәре квалификация имтиханын тапшырмады дип танырга.

46. Квалификация имтиханы нәтиҗәсе граждан хезмәткәренең имтихан кәгазенә (4 нче кушымта) языла.

Имтихан кәгазе рәис, рәис урынбасары, комиссия секретаре һәм утырышта катнашкан аттестацияләү комиссиясе әгъзалары тарафыннан имзалана. Граждан хезмәткәре имтихан кәгазе белән таныша һәм кул куя.

Граждан хезмәткәренең имтихан кәгазе һәм аның белеме, тәҗрибәсе һәм осталыгы (һөнәри дәрәҗәсе) турындагы һәм аңа классы чин бирү мөмкинлеге турындагы бәяләмә граждан хезмәткәренең шәхси документлары тупланмасында саклана.

47. Квалификация имтиханының нәтиҗәләре Департамент тарафыннан ул узганнан соң җиде көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә һәм (яисә) Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә.

48. Квалификация имтиханы нәтиҗәләре нигезендә Департамент «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә квалификация имтиханы тапшырган граждан хезмәткәренә классы чин бирү турында хокукый акт проекты әзерли.

Кабул ителгән хокукый акт нигезендә Департамент тарафыннан граждан хезмәткәренең шәхси документлары тупланмасына һәм аның хезмәт кенәгәсенә (булган очракта) тиешле язма кертелә. Граждан хезмәткәренә классы чин бирү турында мәгълүмат шулай ук аның хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләргә кертелә.

49. Квалификация имтиханын тапшырмаган граждан хезмәткәре әлеге имтихан уздырганнан соң алты айдан да иртәрәк булмаган вакыт эчендә кабат квалификация имтиханы уздыру турында тәкъдим кертә ала.

50. Граждан хезмәткәре Россия Федерациясе законнары нигезендә квалификация имтиханы йомгакларына шикаять бирә ала.

Татарстан Республикасы
Президенты Аппаратында
аттестацияләү һәм квалификация
имтиханы уздыруны оештыру
турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

(форма)

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен**
**АТТЕСТАЦИЯЛӘҮ КӘГАЗЕ**

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)____________________

2. Туган числосы, ае, туган елы________________________________________

3. Һөнәри белеме, гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме булу турындагы мәгълүмат_______________________________________________
(кайчан һәм нинди уку йортын тәмамлаган,
_______________________________________________
белгечлеге һәм әзерлек юнәлеше,
_______________________________________________
квалификациясе, гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме)

4. Аттестацияләү уздыру вакытына биләгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы (алга таба – граждан хезмәте) һәм бу вазыйфага билгеләп куелу вакыты_________________________________________

5. Дәүләт хезмәте стажы (шул исәптән граждан хезмәте стажы)____________
_______________________________________________

6. Гомуми хезмәт стажы ___________________________________________

7. Граждан хезмәте класслы чины ____________________________________
(класслы чин атамасы
_______________________________________________
һәм аның бирелү вакыты)

8. Граждан хезмәткәренә бирелгән сораулар һәм аларга кыскача җаваплар
_______________________________________________
_______________________________________________

9. Аттестацияләү комиссиясе тарафыннан күрсәтелгән кимчелекләр һәм тәкъдимнәр_____________________________________________
_______________________________________________

10. Дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан үткәндәге аттестацияләүдә бирелгән киңәшләрнең үтәлүен кыскача бәяләү_________________________
_______________________________________________
(үтәлгән, өлешчә үтәлгән, үтәлмәгән)

11. Аттестацияләү комиссиясе карары________________________________

(биләгән граждан хезмәте вазыйфасына

туры килә; биләгән граждан хезмәте вазыйфасына туры килә һәм билгеләнгән тәртиптә

югарырак вазыйфага билгеләп кую өчен вакантлы граждан хезмәте вазыйфасын биләү

резервына кертүгә тәкъдим ителә; яңадан һөнәри әзерлекне яисә квалификациясен

күтәрүне уңышлы узган очракта, биләгән граждан хезмәте вазыйфасына туры килә;

биләгән граждан хезмәте вазыйфасына туры килми)

12. Аттестацияләү комиссиясенең сан ягыннан составы____________________

Утырышта аттестацияләү комиссиясенең ____ әгъзасы катнашты.

Бирелгән тавышлар: риза ____, каршы ____

13. Искәрмәләр____________________________________________________

__________________________________________________________________

Аттестацияләү комиссиясе рәисе ______________ ______________________

(имза) (имзаны шәрехләү)

Аттестацияләү комиссиясе рәисе урынбасары ______________ ______________________

(имза) (имзаны шәрехләү)

Аттестацияләү комиссиясе секретаре ______________ ______________________

(имза) (имзаны шәрехләү)

Аттестацияләү комиссиясе әгъзалары ______________ ______________________

(имза) (имзаны шәрехләү)

______________ ______________________

(имза) (имзаны шәрехләү)

Аттестацияләүне уздыру вакыты

________________________

Аттестацияләү кәгазе белән таныштым______________________________

(граждан хезмәткәре имзасы, дата)

(дәүләт органы мөһерен
кую урыны)

__________

Татарстан Республикасы
Президенты Аппаратында
аттестацияләү һәм квалификация
имтиханы уздыруны оештыру
турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

(форма)

РАСЛЫЙМ

______________________________

(документны раслаучы затның вазыйфасы атамасы)

____________ (________________)

(имзасы) (инициаллары, фамилиясе)

20__ елның «___» ___________

**Аттестация чорында аттестацияләнергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәвенә**

**БӘЯЛӘМӘ**

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)____________________
______________________________________________________________________

2. Туган көне, ае, елы __________________________________________________

3. Аттестация уздыру вакытына билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте (алга таба – граждан хезмәте) вазыйфасы һәм аңа билгеләнгән вакыты ______________________________________________

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре (алга таба – граждан хезмәткәре) аларны хәл итүдә (эшләүдә) катнашкан төп мәсьәләләр (документлар) исемлеге_____________________________________________

5. Граждан хезмәткәренең хезмәт дисциплинасын һәм чикләүләрне үтәмәве, тыюларны бозуы, Россия Федерациясенең граждан хезмәте һәм коррупциягә каршы көрәшү турындагы законнарында билгеләнгән хезмәт урынында тәртипкә билгеләнгән таләпләрне һәм йөкләмәләрне үтәмәве турында расланган фактларның булмавы турында мәгълүмат ____________________

6. Граждан хезмәткәренең оештыру сәләте турында мәгълүмат (башка граждан хезмәткәренә карата оештыру-боеру вәкаләтләре булган граждан хезмәткәрен аттестацияләгәндә тутырыла) ______________________________

7. Тәкъдим ителгән бәя *

☐ Биләгән граждан хезмәте вазыйфасына туры килә һәм вазыйфаи үсеш буларак граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен кадрлар резервына кертергә тәкъдим ителә (граждан хезмәткәре биләгән вазыйфа кергән граждан хезмәте вазыйфалары төркемен күрсәтеп яки граждан хезмәткәрен билгеләп кую мөмкин булган югарырак вазыйфалар төркемен күрсәтеп)

☐ Биләгән граждан хезмәте вазыйфасына туры килә

☐ Өстәмә һөнәри белем алган очракта биләгән граждан хезмәте вазыйфасына туры килә

☐ Биләгән граждан хезмәте вазыйфасына туры килми

Аттестацияләнүче граждан хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесенең аңлатмалары (булган очракта) ______________

____________________________________________________________________

| | | |
|---|---|---|
| ______________________ | ____________ | ( ____________________ ) |
| (аттестацияләнә торган граждан хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесенең вазыйфасы) | (имзасы) | (инициаллары, фамилиясе) |

20__ елның «____» ____________

Бәяләмә белән таныштым:

| | | |
|---|---|---|
| ______________________ | ____________ | ( ____________________ ) |
| (аттестацияләнә торган граждан хезмәткәренең вазыйфасы) | (имзасы) | (инициаллары, фамилиясе) |

20__ елның «____» ____________

___________

*Әлеге бәяләмәнең 4–6 пунктлары нигезендә граждан хезмәткәренә куела торган тәкъдим ителүче бәяне билгеләү зарур.

Татарстан Республикасы
Президенты Аппаратында
аттестацияләү һәм квалификация
имтиханы уздыруны оештыру
турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

(форма)

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең белеме, күнекмәләре һәм осталыгы (һөнәри дәрәҗәдә) турында һәм аңа класслы чин бирү мөмкинлеге турында**
**БӘЯЛӘМӘ**

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)___________________

2. Туган көне, ае, елы ________________________________________________

3. Квалификация имтиханы уздыру вакытына билгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте (алга таба – граждан хезмәте) вазыйфасы һәм аңа билгеләнгән вакыты ______________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре (алга таба – граждан хезмәткәре) аларны хәл итүдә (эшләүдә) катнашкан төп мәсьәләләр (документлар) исемлеге _____________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________

5. Граждан хезмәткәренең хезмәт дисциплинасын һәм чикләүләрне үтәмәве, тыюларны бозуы, Россия Федерациясенең граждан хезмәте һәм коррупциягә каршы көрәшү турындагы законнарында билгеләнгән хезмәт урынында тәртипкә билгеләнгән таләпләрне һәм йөкләмәләрне үтәмәве турында расланган фактларның булмавы турында мәгълүмат ______________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________

6. Граждан хезмәткәренең белеме, күнекмәләре һәм осталыгына (һөнәри дәрәҗәдә) нигезле бәяләмә, классны чин бирү мөмкинлеге турында тәкъдимнәр ______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________

| | | |
|---|---|---|
| ______________________ | ____________ | ( ______________________ ) |
| (граждан хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесенең вазыйфасы) | (имзасы) | (инициаллары, фамилиясе) |

20__ елның «____» ___________

Бәяләмә белән таныштым:

| | | |
|---|---|---|
| ______________________ | ____________ | ( ______________________ ) |
| (граждан хезмәткәренең вазыйфасы) | (имзасы) | (инициаллары, фамилиясе) |

20__ елның «____» ___________

__________

Татарстан Республикасы
Президенты Аппаратында
аттестацияләү һәм квалификация
имтиханы уздыруны оештыру
турында нигезләмәгә
4 нче кушымта

(форма)

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең**
**ИМТИХАН КӘГАЗЕ**

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме________________________________

2. Туган елы, числосы һәм ае________________________________

3. Һөнәри белеме, гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме булу турындагы мәгълүмат ________________________________
(кайчан һәм нинди уку оешмасын тәмамлаган, белгечлеге
________________________________
һәм белеме буенча квалификациясе, гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме)

4. Өстәмә һөнәри белем алуы турында мәгълүмат________________________________
________________________________
(өстәмә һөнәри белем алуы йомгаклары буенча квалификациясен күтәрүен яисә
________________________________
квалификация алуын раслаучы документлар (квалификациясен күтәрү турында
________________________________
таныклык, һөнәри яктан яңадан әзерлек турында диплом)

5. Квалификация имтиханы уздыру вакытына билгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте (алга таба – граждан хезмәте) вазыйфасы һәм бу вазыйфага билгеләп куелу вакыты________________________________
________________________________
________________________________

6. Дәүләт хезмәте стажы (шул исәптән дәүләт граждан хезмәте стажы)
________________________________

7. Гомуми хезмәт стажы ________________________________

8. Граждан хезмәте класслы чины________________________________
(класслы чин атамасы һәм
________________________________
аның бирелү вакыты)

9. Граждан хезмәткәренә бирелгән сораулар һәм аларга кыскача җаваплар
________________________________
________________________________

10. Аттестацияләү комиссиясе тарафыннан күрсәтелгән кимчелекләр һәм тәкъдимнәр______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

11. Граждан хезмәткәре тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәр

______________________________________________

______________________________________________

12. Квалификация имтиханы йомгаклары буенча граждан хезмәткәренең белемен, тәҗрибәсен һәм осталыгын (һөнәри дәрәҗәсен) бәяләү__________

______________________________________________

(дәүләт граждан хезмәткәре квалификация имтиханын бирде дип танырга

______________________________________________

һәм аңа граждан хезмәте классны чинын бирергә тәкъдим итәргә;

______________________________________________

дәүләт граждан хезмәткәре квалификация имтиханын бирмәде дип танырга)

13. Аттестацияләү комиссиясенең сан ягыннан составы__________________

Утырышта аттестацияләү комиссиясенең ____ әгъзасы катнашты
Бирелгән тавышлар: риза ____, каршы ____

14. Искәрмәләр______________________________________________

______________________________________________

Аттестацияләү комиссиясе рәисе ______________ ______________________
(имза) (имзаны шәрехләү)

Аттестацияләү комиссиясе рәисе урынбасары ______________ ______________________
(имза) (имзаны шәрехләү)

Аттестацияләү комиссиясе секретаре ______________ ______________________
(имза) (имзаны шәрехләү)

Аттестацияләү комиссиясе әгъзалары ______________ ______________________
(имза) (имзаны шәрехләү)

______________ ______________________
(имза) (имзаны шәрехләү)

Квалификация имтиханын уздыру вакыты

______________________________

Имтихан кәгазе белән таныштым ______________________________
(дәүләт граждан хезмәткәре имзасы, дата)

(дәүләт органы
мөһерен кую урыны)

__________